РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ
БОЛЬШЕКИБЯЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422065, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Большие Кибячи, ул.Ф.Энгельса, 21
тел. (84362) 42-6-24

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ КИБӘЧЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422065, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Кибәче авылы, Ф.Энгельс урам, 21 йорт
тел. (84362) 42-6-24

e-mail: Bkib.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
04.02.2020

КАРАР
№4

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының 2012 нче елның 30 нчы маенда кабул ителгән 13 нче номерлы "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 16.12.2019 ел, №432-ФЗ Федераль закон һәм «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында” Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 01.04.2019 ел, №48-ФЗ Федераль законга туры китереп, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советы

Карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының 30.05.2012 ел №13 карары белән расланган Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 20.3.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«20.3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм төшерү тәртибе, әлеге Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.»;

1.2 12.3 пунктның 6) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«6) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш.”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы А.К. Сафин